ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктында «законнарда» сүзен «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «коммерциячел булмаган оешмалар, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен «Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2012 елның 14 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 пунктта «һәм иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен «, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнар» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 25-ТРЗ